ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
“ ТАТАР ЯЛТАНЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

"24 " сентябрь 2018 г. № 55/1

Чистай муниципаль районы
Татар Ялтаны авыл җирлеге
территориясендә гражданнарга
үзара салым кертү һәм аның акчасын
файдалану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Жирле референдум турында” 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Чистай муниципаль районы “Татар Ялтаны авыл җирлеге” Уставының 11 статьясы нигезендә, Татар Ялтаны авыл җирлеге Советының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 54/1 номерлы карары, Татар Ялтаны авыл җирлеге Башкарма комитетының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 13 номерлы карары белән, Татар Ялтаны муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 1нче һәм 2нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 2018 елда 300 сум күләмендә үзара салым салуны кертүгә һәм җыелган салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә ризамы:

- Татар Ялтаны һәм Изгар авылларында юлларны төзекләндерү һәм карап тоту

( щебенка сатып алу, китертү, щебенка җәю, грейдерлау, кардан чистарту) өчен.

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, авыл җирлегенең халык күпләп җыела торган урыннарга, мәгълүмат стендлары һәм такталарына урнаштырырга.

Татар Ялтаны авыл җирлеге
башлыгы Н.Н.Воляков